Казан шәһәре Совет районының
«Катнаш төрдәге 166нчы Билингваль
балалар бакчасы» муниципаль
автономияле мәктәпкәчә белем
учреждениесе
420071, Парклы ур., 29а
Тел./факс: 234-48-01
e-mail: bds166@tatar.ru

Муниципальное автономное дошкольное
образовательное учреждение
«Билингвальный детский сад № 166
комбинированного вида» Советского
района г. Казани
420071, ул. Парковая,29а
Тел. /факс: 234-48-01
e-mail: bds166@tatar.ru

---

"КИЛЕШЕНДЕ"
166нчы Билингваль балалар
бакчасының өлкән тәрбияче
________ Г.Н.Фахриева

«РАСЛЫЙМ»
166 нчы Билингваль балалар
бакчасының мөдире
__________ Т.Х.Поликарпова
Боерык №______ "__" ______ 20__ ел

# *Беренче һәм икенче төркем балалары өчен "Туган телдә сөйләшәбез" проекты буенча эш программасы.*

## *2021 – 22 нчы уку елы.*

***Татар теле тәрбиячесе: Гарифзянова Л.Р.***

**Аңлатма язуы**

**Эш программасы статусы.**

Программа “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасы башка телләрнесаклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасына, Федераль дәүләт таләпләренә нигезләнеп төзелде.

**Эш программасы структурасы**.

Ана телен өйрәнү буенча эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп өлештән(тематик планлаштыру), мониторинг.

**Эш программасының эчтәлеге.**

*Программаның максаты:* балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү. Төп үзенчәлеге - тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау, телне тоемлау сәләте булдыру.

*Татар теле тәрбиячесенең бурычлары:*

балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын,күзәтүчәнлеген, диалогта катнашу теләген,хәтерне үстерү;

тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;

сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү;

пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү;

әйләнә-тирә табигать объектларына,халык авыз иҗатына,һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү;

тәрбияче, яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү;

тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру.

Режим вакытында I һәм II кече яшьтәгеләр, шөгыльләрдә уртанчылар,зурлар, мәктәпкә әзерлек (татар) төркемендә ана телен өйрәнүгә атнага 3 тапкыр вакыт бирелә. Танып белү эшчәнлеге –39 тема, сөйләм үстерү – 32 тема, матур әдәбият белән таныштыру - 35 тема.

**Укыту – методик комплект**

**1.**Р.К.Шәехова.Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы, Казан – РИЦ, 2012.

2.Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы”
3. Ф.В.Хәзрәтова, З.Г. Шәрәфетдинова, И.Җ. Хәбибуллина. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2012)..
4.“Туган телдә сөйләшәбез”. Аудиоязма(авт.Ф.В. Хәзрәтова).

5.“Туган телдә сөйләшәбез”.Күрсәтмә һәм таратма материаллар(авт.Ф.В. Хәзрәтова).

6.К.В. Закирова. Балачак аланы. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия.-Казан:РИЦ нәшрияты. 2011.

7.К.В.Закирова, Л.Р. Мортазина. Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак. Балалар бакчасында уеннар.- Казан,2012.

8. Гарафиева Г. З. эшкәртмәсендә 2 – 3 яшьлек балалар өчен “Туган телем – әнкәм теле”.

9. Гарафиева Г. З. эшкәртмәсендә 3 – 4 яшьлек балалар өчен “Туган телем – юл башы”.

10. Гарафиева Г. З. эшкәртмәсендә 4 – 5 яшьлек балалар өчен “Туган телем – белем ачкычы”.

11. Гарафиева Г. З. эшкәртмәсендә 5 – 6 яшьлек балалар өчен “Туган тел – саекмас чишмә”.

12. Гарафиева Г. З. эшкәртмәсендә 6 – 7 яшьлек балалар өчен “Туган тел – очар канат”.

**Ана телен өйрәнү буенча тематик планлаштыру**
Программа“Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”на (Р.К. Шәехова, Казан- РИЦ, 2012.), Н. Е. Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы”нигезләнеп төзелде.

## I кече яшьтәгеләр төркеме

| № | Төп темалар | Шөгыльләр саны | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Танышу | 6 | Балаларны бер-берсе һәм тәрбияче белән таныштыру. Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләштерү |
| 2. | Безнең балалар бакчасы | 11 | Баланың социаль мохите буларак,балалар бакчасы  белән таныштыру. Яшьтәшләре белән аралашуның балаларда уңай эмоцияләр тудыруына ирешү. |
| 3. | Көз | 9 | Көз турында күзаллау формалаштыру; табигатькә, кешеләр киемендәге үзгәрешләргә, уңыш жыю, кайбер яшелчә җиләкләр турында беренчел күзаллау формалаштыру; йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Көзен урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. |
| 4. | Мин – дөньяның бер кешесе | 5 | Балада,кеше буларак, үзе турында күзаллау булдыру; кеше гәүдәсенең төп өлешләре һәм аларның ни өчен кирәклеге  белән таныштыру. Нәрсәнең яхшы,нәрсәнең начар булуы, сәламәт тормыш образы турында башлангыч күзаллау булдыру. |
| 5. | Гаилә | 9 | Үз исемен, гаилә әгъзаларының исемнәрен белүләренә ирешү. Гаилә әгъзаларына хөрмәт, үзара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| 6. | Кыш | 6 | Кыш турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә сезон үзгәрешләре,кешеләрнең киеме, балалар бакчасы мәйданы). Балаларның йорт хай ваннары һәм кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Кыш көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Яңа ел бәйрәме | 5 | Яңа елга һәм Яңа ел бәйрәменә кагылышлы эшчәнлекнең барлык төрен (уен, коммуникатив эш чәнлек, хезмәт,танып белү, тикшеренү, продуктив,музыкаль эшчәнлекләр, укулар) оештыру. |
| 8. | Минем әйләнә- тирәм | 15 | Балаларны туган шәһәрләре (авыллары): аның исеме, объектлары (урам,йорт, кибет, шифаханә) һәм транспорт,һөнәрләр (табиб, сатучы, полиция хезмәткәре) белән таныштыру. |
| 9. | Әтиләр - бабайлар | 6 | Гаилә, әти, бабай темасына кагылышлы эшчәлекнең барлык төрләрен оештыру (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү, тикшеренү,продуктив, музыкаль эшчәнлекләр,укулар). |
| 10. | Әниләр - әбиләр | 5 | Гаилә, әни, әби темасына кагылышлы эшчәлекнең барлык төрләрен оештыру (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү, тикшеренү,продуктив, музыкаль эшчәнлекләр,укулар). |
| 11. | Халык иҗаты | 9 | Балаларны халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты (җырлар, бармак уенна ры һ.б.) белән таныш тыру. Балалар эш чәнлеге нең барлык төрләрен оештырганда, фольклор элементларын куллану. |
| 12. | Яз | 12 | Яз турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә,балалар бакчасы мәй данында сезоны үзгәрешләре). Йорт хайваннары һәм йорт кошлары турында белемнәрен киңәйтү. Яз көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. |
| 13. | Җәй | 10 | Җәй турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә, кешеләр киемендә,балалар бакчасы мәй данында сезон үзгәрешләре). Йорт хайваннары һәм кошлары, яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрен киңәйтү. Җәен урман җәнлекләре һәм кош ларының үз-үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. Җылы якларда яшәүче кайбер хайваннар белән таныштыру. |

# II кечкенәләр төркеме

| № | Төп темалар | Сәгать | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 1 | “Исәнме,балалар бакчасы”<br>1.Танышу<br>2.Өйдә кем яши?<br>3. Мин малай, мин кыз<br>4. Мияу белән танышу<br>5.Әйдәгез, танышыйк<br>6. Әйдә дуслашыйк | 6 | Татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту,төрле милләт балалары арасында дуслык тәрбияләү,<br>Сөйләмне,игътибарны,ишетү сәләтен,хәтерне үстерү,тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү,табигать бн кызыксыну уяту.<br>төсне,формасын,зурлыгын билгеләү,сүз байлыгын арттыру,<br>Яңа сүзләрне сөйләмгә кертү,телне өйрәнүгә кызыксыну уяту,авазларны дөрес әйтү<br>Авазларны дөрес әйтергә,аерым сүзләрдә җөмләләрдә куллану,сорауларга җавап бирергә өйрәтү<br>Шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә,фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына ,игътибарларын,әсәргә карата кызыксыну уяту.<br>Сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлау,сөйләмдә активлаштыру,фикерләүне үстерү,туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге уяту |
| 2 | “Уенчыклар”<br>1.Минем яраткан уенчыкларым<br>2. Минем яраткан уенчыкларым<br>3.Карусельгә сәяхәт<br>4.Без уйнарга яратабыз<br>5.Йомшак уенчык карау<br>6.Туп<br>7.Туган көн<br>8.Мияу кунакка килгән<br>9.Уенчыклар кибете | 9 | Уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. Уенчыклар исәбенә сүз байлыгын үстерү. Игътибарлылык тәрбияләү. Балаларда бер-берсенә карата дустанә мөнәсәбәт, уенчыкларга сак караш тәрбияләү.<br>Сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлау,сөйләмдә активлаштыру,фикерләүне үстерү,туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге уяту. Сөйләмне,игътибарны,ишетү сәләтен,хәтерне үстерү,тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү,табигать бн кызыксыну уяту.<br>төсне,формасын,зурлыгын билгеләү,сүз байлыгын арттыру,<br>Яңа сүзләрне сөйләмгә кертү,телне өйрәнүгә кызыксыну уяту,авазларны дөрес әйтү |
| 3 | “Көз”<br>1.Алтын көз<br>2.Көз килде<br>3.Аваз кулҗтурасы. Ө авазы<br>4.Куян үстергән кишер һәм помидор.<br>5.Яшелчә бакчасында. | 9 | Яшелчэлэр турындагы белемнәрен ныгыту,тышкы күренеше,тәме,формасы буенча аера белүләренә ирешү,аңга алуларына,диалогик сөләмнәрен үстерү,сорауларга җавап бирә теләге уяту.<br>Ел фасылының билгеләре бн таныштыру,төсләрне дөрес атау,авазлар әйтелешен ныгыту,игътибарларын,хәтерләрен,бәйләнешле сөйләмне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6.”Шалкан” әкияте.<br>7.Җиләк-җимеш бакчасында<br>8.Бакчада алмалар өлгерде..<br>9.Уйный-уйный саныйбыз | | үстерү. Өйрәнелгән сүзләрне сөйләмдә куллану,ныгыту,хәтерне үстерү,дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү,төсләрне дөрес әйтергә өйрәтү ,кыска җөмләләр төзи белергә өйрәтү<br>Сөйләм телен үстерү,төсләрне аерып әйтә белергә, күргәненңне аңлата белергә өйрәтү,<br>Әкиятнең эчтәлеге бн таныштыру,халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү,<br>истә калдырырга сәнгатле итеп сөйләргә өйрәтү,<br>Шигри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтү.<br>Күргәннәрне әйтеп сөйләп бирә белүләренә,авазларны дөрес итеп әйтүләренә,<br>авазларны дөрес әйтергә ярдәм итү,<br>Матурлыкка соклану хисе уяту |
| 4 | “Гаилә”<br>1.Өйдә кем яши?<br>2. Безнең гаилә.<br>3.Качышлы уйныйбыз<br>4.Тату гаилә<br>5.Минем дуслар<br>6.Әйдәгез, дуслашыйк<br>7.Минем туганнарым<br>8. Безнең гаилә.<br>9.Әби күчтәнәче<br>10.Дустыңны сыйла<br>11.Сөт, чәй<br>12.Кунакка барабыз | 12 | Гаилә әгъзалары белән таныштыруны дәвам итү,соруны аңлап дөрес җавап бирү,”Ә”авазының дөрес әйтелеше өстендә эшләү<br>Сүзлек запасын баету,диалогик сөйләм үстерү,җырның сүзләрен ә кушылу теләге уяту<br>Шигри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә,аерым сүзләрне,фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларга,хәтерне,әсәргә карата кызыксыну уяту. Сорауларга тулы җавап бирүләренә,аваз әйтемнәрен дөрес кабатларга өйрәтү,сүзлек байлыгын  үстерү |
| 5 | “Кыш”<br>1.Кар ява<br>2.Алсуны урамга киендерәбез<br>3. А.Алиш “Куян кызы”<br>4.”Чанада шуабыз” рәсемен карау<br>5.Кышкы уеннар<br>6.”Куяннар” уенын өйрәнү | 6 | Рәсемне карарга,эчтәлеген аңларга,эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү,диалогик сөйләмнәрен,күрсәтмә-образлы фикерләүләрен үстерү.сүзлек запасын баету,уен вакытында авазлар куллану. яңа сүзләр кертү,фикерләү сәләтен үстерү,диалогик,монологик сөйләмне үстерү,уйлау-фикерләү сәләтен үстерү.Сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү,диалогик сөйләмен,сөйләм сулышын үстерү. |
| 6. | “Яңа ел бәйрәме”<br>1.Тиздән чыршы бәйрәме | 9 | Уенчыкларның төсе,формасы,төрләре бн таныштыру,диалогик сөйләм үстерү,сорауларга җөмлә бн җавап бирергә өйрәтү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2.Б.Рәхмәтнең “Кыш бабай”шигырен ятлау<br>3.”Уйныйбызда, җырлыйбыз<br>4.Без бәйрәмгә әзерләнәбез<br>5.Бәйрәм концерты<br>6.Яңа ел бәйрәме | | Бәйлек сүзләрне(эчендә,артында,астында) кулланырга,сорауларга җавап бирергә.Табышмак чишәргә өйрәтергә,җәнлекләрнең кышкы тормышлары турындагы белемнәрен киңәйтергә,рәсемдә күргәннәрне сөйли белергә өйрәтү. Шигри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә,истә калдырырга сәнгатле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү,сүзлекне баету.хәтерне игтибарны үстерү |
| 7. | “Минем йортым,минем шәһәрем”<br>1.Минем шәһәрем<br>2. Мин “Камаз”оныгы.<br>3 Әлли-бәлли итәргә бишек җыры уку.<br>4.Безнең урам<br>5. Алсуның яңа өе.<br>6.Алсуда кунакта | 6 | Авазларның артикуляциясен ныгыту,танып белү активлыкларын формалаштыру матур итеп сөйли белергә өйрәтүне дәвам итү<br>Бәйлек сүзләрне(эчендә,артында,астында) кулланырга,сорауларга җавап бирергә,ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү,игтибарны,тәрбияче күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү. Табышмак чишәргә өйрәтергә,истә калдырырга сәнгатле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү,сүзлекне баету.хәтерне- игьтибарны үсте,аерым сүзләрне,фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына,әсәргә карата кызыксыну уяту |
| 8. | Безнең авылда<br>1.Безнең авылда<br>2.Зурлар һәм кечкенәләр<br>3.”Кем нәрсә ярата” татар халык әкиятен сөйләү<br>4.”Песи һәм песи балалары”рәсемен карау<br>5.Ж.Тәрҗемановның “Үзен бик чиста йөртә” шигырен уку<br>6.”Кем МИЯУ дип әйтте?<br>7.Йорт кошлары<br>8.Р.Батулланың “Елак этәч” әсәрен уку<br>9.Без уйныйбыз | 9 | Йорт хайваннарын таный һәм аера белергә өйрәтү. Хайваннар турында кайгыртучанлык хисләре уяту<br>Сүз байлыгын арттыру. Әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү. Сөйләмне,игътибарны,ишетү сәләтен,хәтерне үстерү. Йорт кошлары белән таныштыру. |
| 9. | “Ватанны саклаучылар көне”<br>1.Зур гаилә<br>2. Безнең этиләр һәм абыйлар<br>3.Бабайга кунакка барабыз<br>4. Ватанны саклаучылар көне<br>5. Очучылар<br>6.З.Туфайлованың.”Шофер булам”шигырен уку. | 6 | Әңгәмәдә катнашырга,үзеңнең яраткан кешең турында сөйли белергә,матур ,ягымлы сүзләр кулланырга өйрәтуне дәвам итәргә,профессияләр турында белемнәрен үстерергә<br>Киемнәрне исемнәрен дөрес итеп атарга,шигырләрне матур итеп авазларны әйтергә өйрәтү. Башкаларның сөйләвен тыңлый белергә,үзеңнеңдә катнашу теләген уяту . Аңга алуларын,игтибарларын,диалогик,монологик сөйләмнәрен үстерү.Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү<br>Гаилә лексикасын ныгыту,диалогик сөйләмне активлаштыру,хәтер сәләтен үстерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә,өйрәтү,аерым<br>сүзләрне,фразаларны кабатлау, |
| 10 | “Сигезенче Март”<br>1.Минем әнием<br>2. Кояш гомере телим мин,әнием сиңа!<br>3.Без әнигә булышабыз<br>4.Әбигә кунакка барабыз<br>5.Мин әнинең ярдәмчесе<br>6.Азат кунак чакыра | 8 | Гаиләгә,әниләргә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү,сюжетлы<br>рәсемнәрне эчтәлеген аңларга ,сүз байлыгын арттырырга,куелган<br>сорауларга кыска җөмлә бн җавап бирүне үстерү<br>шигыр ятлау теләге уяту,сүзләрне матур итеп ачык итеп әйтергә<br>күнектерү,милли йолаларга,гореф гадәтләргә мәхәббәт тәрбияләү.<br>(Ә)авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү,әңгәмәдә катнашуга<br>тарту,хәтерне,диалогик сөйләм формасын үстерү. |
| 11 | “Кыргый хайваннар”<br>1.Урманда<br>2.Аю белән куян<br>3.”Өч аю” әкияте | 3 | Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. Логик<br>фикерләү сәләтен үстерү. Кыргый хайваннарны таный белергә өйрәтү.<br>Әкиятнең эчтәлеген сораулар ярдәмендә сөйләргә өйрәтү |
| 12 | Әкияттә кунакта<br>1.”Теремкәй”рус халык әкиятен сөйләү<br>2.Кыргый хайваннар<br>3. ”Төлке ,куян һәм әтәч”әкиятен сөйләү,<br>сәхнәләштерү | 3 | Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. Сюжетның эзлеклеген билгели<br>белергә өйрәтү.Балаларның кыргый хайваннар турындагы белемнәрен<br>киңәйтү. Дуслык хисләре тәрбияләү. Сәнгатьле сөйләм үстерү |
| 13 | “Яз”<br>1.Урамда яз.<br>2.Яз җитте<br>3.Яз җыры<br>4.”Кояш чык, чык...”<br>5Язгы күренешләр<br>6.Ак аю кунакка килгән<br>7.Кошлар<br>8.Х.Вахитның “Уңган сыерчык” шигырен уку<br>9.Без уйныйбыз | 9 | Күзәтүчәнлекне,сүз байлыгын үстерү,диалогик сөйләмне ,кечкенә<br>җөмләләр куллануны камилләштерү<br>Сөйләм телен үстерү,диалогик сөйләм куллану,зулык төшенчәсен<br>аңлатып бирә белүләрен булдыру,үз теләгеңне башкаларга аңлатып<br>бирә алуларыыыын булдыру. Шигри әсәрне тыңлый һәм аңлый<br>белергә,өйрәтү,аерым сүзләрне,фразаларны тәрбияче артыннан дөрес<br>итеп кабатлауларына ирешү,аңга<br>алуларын,игтибарларын,хәтерләрен,хәрәкәт активлыкларын<br>үстерү,әсәргә карата кызыксыну уяту. |
| 14 | Бәйрәмнәр<br>1.Бәйрәмгә барабыз<br>2.”Балалар бакчасында бәйрәм” дигән рәсем карау<br>3.”Урманда зур концерт”анимацион сюжет карау | 3 | Диалогик сөйләм,сүз байлыгын үстерү. Күтәренке кәеф<br>булдыру.”Бәйрәм” төшенчәсен аңлату. |
| 15 | Җәй<br>1.Мультфильмда кунакта<br>2.М.Мазуновның “Кәҗә” шигырен уку<br>3.Матур җәй килә безгә | 10 | Рәсемне карарга,эчтәлеген аңларга,эчтәлеге буенча сорауларга җавап<br>бирергә өйрәтүне дәвам итү,диалогик сөйләмнәрен,күрсәтмә-образлы<br>фикерләүләрен үстерү.<br>Сөйләм телен үстерү,диалогик сөйләм куллану,зулык төшенчәсен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4.Мин җәйне яратам<br>5.”Карга”эндәшен уку<br>6.Саф һавада<br>7.Экология сукмагы буенча сәяхәт<br>8.Без уйныйбыз | | аэлатып бирә белүләрен булдыру,үз теләгеңне башкаларга аңлатып бирә алуларыыын булдыру<br>Аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү,йорт хайваннары,кошлары турындагы белемнәрен киңәйтү,сүзлекне активлаштыру<br>Шигри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә,өйрәтү,аерым сүзләрне,фразаларны тәрбияче артыннан дөрес итеп кабатлауларына ирешү,аңга алуларын,игтибарларын,хәтерләрен,хәрәкәт активлыкларын үстерү,әсәргә карата кызыксыну уяту. |

## Зурлар төркеме

| № | Проект темалары | сәгать | Эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|
| 1 | Минем бакчам. | 3 | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт. Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында» Шигырь ятлау: М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч» |
| 2 | Мин яратам сине, Татарстан | 4 | Әңгәмә. «Туган ил кайдан башлана?» «Башкалабыз – Казан» Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан» “Баулым - туган ягым” |
| 3 | Яхшы сүз – җан азыгы | 2 | Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз» |
| 4 | Абдулла Алиш иҗаты | 2 | «А.Алиш – балалар язучысы» Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән аккош» |
| 5 | Хуш киләсең, ямьле көз! | 4 | Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр үтте, көзләр җитте» Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать» Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз» шигырь уку Ф. Яруллин “Көзге табын” |
| 6 | Көз күчтәнәчләре | 3 | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. «Көзге могҗиза» Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе» Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә» |
| 7 | Икмәк – яшәү терәге | 3 | Игенче хезмәте белән танышу» Әңгәмә. «Икмәк – тормышның нигезе» Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте |
| 8 | Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары | 6 | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Безнең гаилә» «Әби-бабайларны хөрмәтлик» Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием» «Һәркемнең үз йорты бар» Әңгәмә. «Йорт җиһазлары» Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи» |
| 9 | Табын янында | 4 | Савыт-саба кибетенә сәяхәт Чагыштырма хикәя төзү: «Чәйнек белән самавыр» Әңгәмә. «Мин кунак яратам» Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?» |
| 10 | Киемнәр дә безне бизиләр | 2 | Кием-салым кибетенә сәяхәт Әңгәмә. «Милли киемнәр» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Саулык – зур байлык | 3 | «Су, һава һәм кояш – безнең белән гел юлдаш!» Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез» |
| 12 | Исеменә күрә – җисеме | 2 | Әңгәмә. «Исемең матур, кемнәр куйган?» «Без дә хокуклы» |
| 13 | Салкын кыш. Кышкы уеннар | 5 | Әңгәмә. «Без суыктан курыкмыйбыз» Тәҗрибә. «Предметның бер хәлдән икенче хәлгә күчүе» Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар» Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы» Баулы боз сараена экскурсия |
| 14 | Бездә кышлаучы кошлар | 4 | Балалар бакчасы тирәли экскурсия. «Җимнәр сибәм кошларга» Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә» Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк» Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә» |
| 15 | Кыргый хайваннар | 4 | |
| 16 | Йорт хайваннары һәм кошлары | 3 | Төркемдә уен оештыру. «Зоопаркка сәяхәт» Рәсем буенча хикәя төзү. «Куяннар» Әкият уку, сәхнәләштерү: «Төлке белән бүре». Татар халык әкияте Әкият уку: «Бүре аларны нигә ашаган». Болгар халык әкияте |
| 17 | Транспорт | 3 | «Җир өсте, һава, су транспорты» Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. «Йөк машинасы һәм җиңел машина» Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде» |
| 18 | Юл йөрү кагыйдәләре | 3 | «Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре» Әңгәмә. «Велосипед – минем дустым» Шигырь ятлау: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе» |
| 19 | Хезмәт төбе – хәзинә | 3 | Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. «Хезмәткә хөрмәт» Әңгәмә. «Кем булырга?» Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар» |
| 20 | Кунак булсаң – тыйнак бул! | 2 | Әңгәмә. «Сүз эчендә энҗе бар» Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Табын кагыйдәләре» |
| 21 | Россия – зур дәүләт | 2 | «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел ...» Әңгәмә: «Теле барның – иле бар» |
| 22 | Батырлыкта – матурлык | 2 | «Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар» Шигырь уку: Җ.Дәрзаман. «Солдат булдым» |
| 23 | Заманча әкиятләр | 1 | «Винни-пух кунакка бара» – минем яраткан мультфильмым» |
| 24 | Кояш гомере телим мин, әнием,сиңа! | 3 | Әңгәмә. «Әни кирәк» Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре» Шигырь уку Ф. Яруллин “Әниләр бәйрәмендә” |
| 25 | Без язны яратабыз | 5 | Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү Рәсем буенча хикәя төзү. «Яз» Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә» Тәҗрибә үткәрү. «Суган утырту» |
| 26 | Безнең канатлы дусларыбыз | 4 | Терәк сораулар буенча рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү. «Сыерчык |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белән карга яз килүгә шатлана». Уен-викторина. «Кошлар – безнең дусларыбыз!» Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач» Ф. Яруллин “Хәтерсез күке” |
| 27 | Хәрәкәттә – бәрәкәт | 2 | «Минем яраткан спорт төре» Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар» |
| 28 | Су яшәү чыганагы | 2 | Әңгәмә: «Яңгыркаем, яу, яу!» Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре» |
| 29 | Уттан саклан! | 2 | Әңгәмә. «Янгын куркынычсызлыгы» Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле» |
| 30 | Бүлмә гөлләре | 3 | «Хуш исле нәфис гөлләр» Тәҗрибә. «Кояш, су һәм һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте» Безнең бакча гөлләре (төркемнәр буенча сәяхәт) |
| 31 | Галәм киңлекләре | 1 | «Планетарийга сәяхәт» уены |
| 32 | Г.Тукай иҗаты | 4 | «Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты» Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк» Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый» Без – яшь тукайчылар (Викторина) |
| 33 | Урман – Җиребезнең матурлыгы, байлыгы | 5 | Урман почмагына экскурсия «Камканы күзәтү» «Кызыл китап нәрсә ул?» Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй».”Тере почмакка” экскурсия. |
| 34 | Җиңү алып килде май | 2 | Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү» Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай» |
| 35 | Чәчәкләр – тормыш яме | 1 | Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме» |
| 36 | Алдакчы, саран булма | 1 | Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир» |
| 37 | Хуш киләсең, ямьле җәй! | 1 | Хуш киләсең, ямьле җәй! |

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

| № | Проект темалары | Сәгать | Эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Белем бәйрәме. | 3 | 1.Мәктәпкә экскурсия.”Исәнме, мәктәп!” 2.Әңгәмә: “Белем бәйрәме”. 3.Хикәя уку: М.Хәсәнов “Сара мәктәпкә бара”. |
| 2. | Аралашу әдәбе. | 2 | 1.Әңгәмә: “Тәмле сүз-җан азыгы” 2. Хикәя эчтәлеген сөйләү: В.Осеева “Тылсымлы сүз” |
| 3. | Туган ягым- яшел бишек. | 6 | 1.“Минем туган җирем”. 2. Әңгәмә: “Минем гүзәл халкым”. 3. “Туган ягым язучылары”. 4.”Татарстан буйлап сәяхәт”. 5. Әңгәмә: “Чал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тарихлы Казаным".6. Шигырь уку: Ә. Синегулов "Татарстан җирләре". |
| 4. | Абдулла Алиш | 2 | 1.А.Алиш иҗаты белән танышу. 2. Әкиятнең эчтәлеген сөйләү "Сертотмас үрдәк" |
| 5. | Алтын көз! | 3 | 1.Урман почмагына сәяхәт. 2.Рәсем буенча хикәя төзү: "Алтын көз" 3. Шигырь ятлау: М.Җәлил "Көз житте". |
| 6. | Яшелчә, җиләк-җимеш. | 6 | 1.Бакчада көзге эшләр. 2.Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү "Мин уңыш җыйдым". 3. Шигырь уку: Х. Халиков "Дәү әнием бакчачы". 4. Көз күчтәнәчләре. 5. Рәсем буенча хикәя төзү: "Кәзге эшләр" 6. . Шигырь уку:Н.Мадьяров "Балан" |
| 7. | Икмәк- яшәү терәге. | 3 | 1. Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә. 2. Картина карау И. Шишкин "Арыш басуы" 3. Шигырь уку:Р. Вәлиева "Ашлар солтаны". |
| 8. | Гаилә һәм йорт җиһазлары. | 4 | 1.Минем өем, өй җиһазлары. 2. Әңгәмә "Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?"3. Иҗади хикәя төзү: "Тату гаилә" 4. Шигырь уку: З. Туфайлова "Минем гаиләм". |
| 9. | Ашамлыклар һәм савыт- сабалар. | 3 | 1. Ашханәгә экскурсия. 2.Әңгәмә "Кунак чакырдык". 3. Хикәянең эчтәлеген сөйләү:С. Сәүбанова "Ботка нигә тәмле?" |
| 10. | Милли киемнәр. | 3 | 1.Танышу уены "Әбиемнең серле сандыгы". 2. Чагыштырып хикәя төзү "Кием кешене бизи". 3. Шигырь уку: Р.Вәлиева "Кәләпүшем, кәләпүш". |
| 11. | Кыш. Кышкы уеннар. | 6 | 1.Экскурсия "Килеп житте матур кыш". 2. Әңгәмә "Паркта минем күргәннәрем". 3. Шигырь ятлау: Г.Латыйп "Кыш килде". 4. Боз һәм бозлыклар. 5. Иҗади хикәя төзү "Кышкы уеннар". 6. Язма сөйләм "Кыш бабайга хат". |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Кыргый хайваннар. | 2 | 1. Кайда, ничек кышлыйлар? 2. Рәсем буенча хикәя төзү “ Кыш. Тиеннәр”. |
| 13. | Йорт хайваннары һәм кошлар. | 3 | 1. Авылда ишегалды”. 2. Картина буенча хикәя төзү “Йорт хайваннары. Ат белән колын”. 3. Әкият эчтәлеге сөйләү “Үрдәк беренчелекне алган”. |
| 14. | Кышлаучы кошлар. | 3 | 1.Кошларны күзәтү “Безнең канатлы дусларыбыз”. 2. “Коәларга ярдәм итик”. 3. Калмык халык әкиятен уку “Күңелле чыпчык белән күңелсез карга”. |
| 15. | Транспорт, юл йөрү кагыйдәләре. | 3 | 1. Транспорт төрләре белән танышу. 2. Әңгәмә “Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәр көнне”. 3. Шигырь ятлау: Г. Юнысова “Светафор”. |
| 16. | Һөнәрләр. | 4 | 1. Балалар бакчасы буйлап сәяхәт: “Безне җырларга кем өйрәтә?” 2. Әңгәмә “Әти- әниләр һөнәре”. 3. Шигырь уку: Э.Мөэминова “Фокусчы” 4. Укытучы һөнәре белән танышу. |
| 17. | Мультфильда кунакта. | 2 | 1.Әкиятне дәвам итеп сөйләү “Күчтәнәчтә” кунакта”. 2. Әңгәмә “Әкиятләр илендә”. |
| 18. | Мин дөньяның бер кешесе. | 2 | 1.Әңгәмә “Мин бәхетле- мин хокуклы”. 2. Тигез хокук белән яшик бу җирдә. |
| 19. | Мин һәм минем сәламәтлегем. | 3 | 1.Шифаханә (шәфкать туташы бүлмәсе). 2. Фикер алышу “Сәламәтлек – зур байлык”. 3.Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Монасыйпов “Шифалы табиблар”. |
| 20. | Муса Җәлил. Ил сакчылары. | 3 | 1.Кемнәр алар- ил сакчылары. 2. Муса Җәлил – бөек шагыйребез”. 3.Шигырь уку: Р. Корбан “Җәлил турында җыр”. |
| 21. | Халыкара телләр көне. | 3 | 1.Фикер алышу: “Дуслык- бөек көч”. 2.Әңгәмә “Россия- безнең илебез”. 3. Шигырь ятлау: Х.Халиков “Сөйләшсәләр безнеңчә”. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | Бүлмә гөлләре. | 3 | 1.Тәҗрибә үткәрү: “Ни өчен орлыкларны,үсемлекләрне балчыкка утырталар?” 2.Хикәя төзү: “Кактус белән фикус гөлен чагыштыру”. 3.Шигырь уку:Ә.Габиди “Минем гөлләрем”. |
| 23. | Ямьле яз. | 4 | 1.Экскурсия “Туган якка яз килде”. 2.Эчтәлекле рәсемнәр буенча хикәя төзү “Яз.Сыерчыклар”. 3. Шигырь уку:Н.Мәдьяров “Көләч яз”. 4.Күзәтү “Ак болытлар ага зәңгәр күктә”. |
| 24. | Исәнмесез, кошкайлар! | 2 | 1.Күчмә кошлар безгә яз алып килде. 2. Шигырь ятлау:Г.Юнысова “Карга”. |
| 25. | Урман. Кызыл китап. | 4 | 1.Нәрсә ул Кызыл китап? 2.Әңгәмә “Урман- безнең байлыгыбыз”. 3.Хикәянең эчтәлеген сөйләү Р.Төхвәтуллин “Шомырт нигә елый?” 4.Хикәянең эчтәлеген сөйләү М.Пришвин “Алтын болын”. |
| 26. | Китап кайдан килә? | 3 | 1.Китапханәгә экскурсия. 2. Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү “Китап кибете”. 3. Шигырь уку: Х.Халиков “Китап докторы”. |
| 27. | Космос | 3 | 1.Нәрсә ул Кояш системасы? 2.Әңгәмә “Космонавтика көне”. 3. Шигырь уку:Йолдыз “Сәлам, галәм!” |
| 28. | Спорт | 3 | 1.Олимпиада. 2.Рәсем буенча хикәя төзү “Спорт мәйданчыгында”. 3.Шигырь ятлау:Г. Юнысова “Зарядкага бас”. |
| 29. | Г. Тукай иҗаты. | 4 | 1.Әдәби викторина Мультфильмда кунакта”. 2.Сәхнәләштерү “Кызыклы шәкерт”. 3. Шигырь уку:”Эш беткәч, уйнарга ярый”. 4.Г.Тукай һәм балалар” |
| 30. | 9 май- Җиңү көне. | 2 | 1.Алар безгә җиңү бүләк итте. 2.Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Л.Кассиль “Күңелләрдә мәңге сакланыр”. |
| 31. | Хуш, бакчам, исәнме, мәктәп! | 3 | 1.Без барабыз мәктәпкә. 2.Сәхнәләштерү: Г.Тукай “Һәркем эштә”. 3. Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт “Мәктәпкә”. |

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр**

**Кечкенәләр төркеме**

**(Үткәрү вакыты 5—14 ноябрь)**

**1. БАЛАЛАРНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ**

*1. «Бу нәрсә?» дидактик уены*

*Материал:* уенчыклар, җиләк-җимеш, яшелчәләр сурәтләнгән предметлы рәсемнәр.

*Диагностик биремнең эчтәлеге.*

Тәрбияче балага уенчык (машина, курчак, туп) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша. Аннары предметларның өлешләрен күр сәтергә тәкъдим итә.Мәсәлән: «Машинаның кабинасын күрсәт. Кузовын күрсәт.Тәгәрмәчләрен күрсәт».Тәрбияче балага җиләк-җимешләр (алма, груша, слива)рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергәкуша: «Бу нәрсә?» Балалардан җиләк-җимешләрнең төсләрен (кызыл, яшел, сары) сорый.Тәрбияче балага яшелчәләр (кишер, кыяр, помидор) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша:«Бу нәрсә?» Аннары яшелчәләрнең төсләрен сорый.

*2. «Син кем?» дидактик күнегүе*

*Диагностик биремнең эчтәлеге*

Тәрбияче баланы үзе янына чакыра, аңа сораулар бирә:«Синең исемең ничек?» «Ә минем исемем ничек?» «Ул —кыз, ә син кем?» «Башыңны күрсәт әле. Кая синең борының(күзләрең, колакларың, кулларың, аякларың)? »

Бәяләү критерийлары: бала, предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавапбирә алмый — 1 балл;бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә — 2 балл; бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ**

*1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены*

*Материал: т*абибә, шофёр, сатучы сурәтләнгән сюжетлы рәсемнәр.

*Диагностик биремнең эчтәлеге*

Тәрбияче балага табибә төшерелгән сюжетлы рәсем күр сәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Табибә.) «Ул нәрсә эшли?» (Тыңлый.) «Ул кемне дәвалый?» (Малайны дәва лый.) Тәрбияче балага шофёр төшерелгән сюжетлы рәсем күрсә тә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Шофёр.) «Шофёр кайда утыра?» (Кабинада утыра.) «Ул нишли?» (Машина йөртә.) Тәрбияче балага сатучы төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Сатучы.) «Сатучы кайда эшли?» (Кибеттә.) «Ул нәрсә эшли?» (Ул әйбер сата.)

*Бәяләү критерийлары*: бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый — 1 балл; бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — 2 балл; бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә, исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ**

*1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены*

*Материал:* песи, эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык рә семнәре.

*Диагностик биремнең эчтәлеге*. Тәрбияче балага песи (эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык)рәсемнәре күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Эт.) «Эт ничек өрә?» («Һау-һау!») «Бу нәрсә?» (Песи.) «Песи ничек кычкыра?» («Мияу-мияу!») «Бу нәрсә?» (Әтәч.) «Әтәч ничек кычкыра?» («Кикрикү-үк!») «Бу нәрсә?» (Сыер.) «Сыер ничек мөгри?» («Му-у!») «Бу нәрсә?» («Күгәрчен.) «Күгәрчен ничек гөрли?» («Гөр-гөр!») «Бу нәрсә?» (Чыпчык.) «Чыпчык ничек чыркылдый?» («Чырык-чырык!»)

*Бәяләү критерийлары*: бала 1—2 биремне генә үти ала — 1 балл;бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — 2 балл; бала биремнәрне теләп башкара, аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — 3 балл.

**4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ**

*1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә*

*Материал*: уйнаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

*Диагностик биремнең эчтәлеге*

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә юнәлтә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кем ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»

*Бәяләү критерийлары*: бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә — 1 балл; бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә — 2 балл; бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасыбелән яки тәрбияче кушуы буенча, рәсемдә сурәтләнгәннесөйли ала — 3 балл.10—12 балл: югары дәрәҗә; 6—9 балл: уртача дәрәҗә; 3—5 балл: түбән дәрәҗә

**ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР (Үткәрү вакыты21—31 март)**

**1. БАЛАНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ**

1. *«Бу нәрсә?» дидактик уены*

*Материал*: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән рәсемнәр.
*Диагностик биремнең эчтәлеге*
Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Савыт-саба.)
Тәрбияче балага йорт җиһазлары (караваt, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Йорт җиһазлары.)Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны
атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (Йорт хайваннары.)
Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (Кыргый хайваннар.) Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Киемнәр.)
*Бәяләү критерийлары*: бала, предметларның исемен атаганда, авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана белми — 1 балл; предметларның исемен дөрес атый, гомумиләште рү че сүзләрне белдергәндә, хаталар җибәрә — 2 балл;предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүчесүзләрне дөрес билгели — 3 балл.

**2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ**

*1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены*
*Материал:* китап укучы әни, өреп торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән рәсемнәр.
*Диагностик биремнең эчтәлеге*
Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Әни.) «Әни нәрсә эшли?»
(Укый.) «Әни нәрсә укый?» (Әни китап укый.)Тәрбияче балага өреп торган эт төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Эт.) «Эт нәрсә эшли?» (Эт өрә.) «Ул ничек өрә?» (Эт «һау-һау» дип өрә.)Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Малай.) «Малайның исеме ничек?» (Бала малайга исем биреп карый.) «Малай нишли?» (Малай уйный.) «Ул нәрсә белән уйный?» (Ул машина белән уйный.)
Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Кыз.) «Кызның исеме ничек?» (Бала кызга исем бирә.) «Кыз нәрсә эшли?» (Кыз рәсем ясый.) «Ул нәрсә белән рәсем ясый?» (Ул карандаш белән рәсем ясый.) «Кыз нәрсә рәсеме ясый?» (Кыз кояш рәсеме ясый.)
*Бәяләү критерийлары*: бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячнең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, бала хаталар ясый — 1 балл; бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячнең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — 2 балл; бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячнең сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячнең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ**

1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга рәсемнәре.
Диагностик биремнең эчтәлеге. Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) рәсеме күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Ат.) «Ат ничек кешни?» («Ми-һа-һай!») «Бу нәрсә?» (Кәҗә.) «Кәҗә ничек кычкыра?» («Ми-ки-ки!») «Бу нәрсә?» (Тавык.) Тавык ничек кыткылдый? («Кыт-кытыйк!») «Бу нәрсә?» (Каз.) «Каз ничек каңгылдый?» («Ка-ка-ка!») «Бу нәрсә?» (Карга.) «Карга ничек каркылдый?» («Кар-кар!»)
Бәяләү критерийлары: бала 1—2 биремне генә үти ала — 1 балл; бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — 2 балл; бала биремнәрне теләп башкара. Аваз иялртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — 3 балл.

**4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ**

1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә
Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.
Диагностик биремнең эчтәлеге. Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә җәлеп итә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кемнәр ясалган? Балалар нәрсәэшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»
2. «Йомры Икмәк» әкиятен сәхнәләштерү
Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларны сәхнәләштерүдә катнашырга чакыра.
Бәяләү критерийлары: бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый — 1 балл; бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргәөстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә, таныш әкиятнесәхнәләштерүдә катнаша — 2 балл;
Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы яки тәрбияче үтенече буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә, эзлеклелекне саклап, сәхнәләштерүдә теләп катнаша — 3 балл. 10—12 балл: югары дәрәҗә, 6—9 балл: уртача дәрәҗә,3—5 балл: түбән дәрҗәдә.

**Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече**
**(зурлар төркеме)**

## Танып белү

Югары дәрәҗә (3 балл). Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.
Уртача дәрәҗә (2 балл). Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.
Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

## Аралашу

Югары дәрәҗә (3 балл). Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.
Уртача дәрәҗә (2 балл). Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

**Матур әдәбият уку**

Югары дәрәҗә (3 балл). Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә.
Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аергнда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга
тулы итеп сөйләми.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

**Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече**
**(мәктәпкә әзерлек төркеме)**

## Танып белү

Югары дәрәҗә (3 балл). Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрестуклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә. Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә ала), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматы бар.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйләгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә, үзлектән төзәтә белә. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы тулы түгел.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, әмма аларны төркемләми. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.

## Аралашу

Югары дәрәҗә (3 балл). Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана ала. Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларны аз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә, хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый; вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә.Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төземи.

**Матур әдәбият уку**

Югары дәрәҗә (3 балл). Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштерелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный. Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

Уртача дәрәҗә (2 балл). Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь) хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелек җитми. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә, хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, хаталар җибәрә, күп очракта үзлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.

Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл). Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

**Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | Сөйләмнең грамматик ягы | Аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |